КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1265

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турында» 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турында» 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 9 октябрь, 507 нче; 2009 ел, 6 апрель, 201 нче; 2009 ел, 19 июнь, 403 нче; 2011 ел, 21 гыйнвар, 33 нче; 2011 ел, 30 декабрь, 1104 нче; 2012 ел, 26 декабрь, 1151 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 938 нче; 2015 ел, 20 гыйнвар, 23 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 817 нче; 2017 ел, 15 февраль, 85 нче һәм 2017 ел, 29 декабрь, 1073 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы нигезләмәдә:

3.2 пунктның 3.2.2 пунктчасында «2018 елның 31 декабренә» сүзләрен «2019 елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта:

4.1.1 пунктчада «2018 елның 31 декабренә» сүзләрен «2019 елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.2 пунктда «2018 елның 31 декабренә» сүзләрен «2019 елның 31 декабренә»

сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Дәүләткә карамаган (өстәмә) пенсия билгеләү өчен Катнашучы соңгы эш урыны буенча бюджет өлкәсе җитәкчесе исеменә бу Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча гариза кертә.

Гаризага әлеге Нигезләмәгә 1.1 нче кушымтага ярашлы форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә язмача ризалык, оешманың кадрлар хезмәтендә, яшәү урыны буенча яки нотариаль таныкланган паспорт күчермәсе, хезмәт кенәгәсе күчермәсе, Россия Федерациясенең пенсия законнары нигезендә пенсия билгеләүне раслый торган документ күчермәсе, инвалидлык билгеләнгәндә – шулай ук инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә күермәсе теркәлә.»;

5.5 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

5.14 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгына, Татарстан РеспубликасыСпорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

5.15 пунктта «2018 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча» сүзләрен «2019 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

6.5 пунктның икенче абзацында «оешманың кадрлар хезмәтендә» сүзләреннән соң «эш урыны буенча яки дәүләтнеке булмаган (өстәмә) пенсия билгеләү турында гариза бирү урыны буенча» сүзләрен өстәргә;

6.6 пунктта «оешманың кадрлар хезмәтендә» сүзләреннән соң «эш урыны буенча яки дәүләтнеке булмаган (өстәмә) пенсия билгеләү турында гариза бирү урыны буенча» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 2, 3 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәләләр).

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 декабрь, 1265 нче карары редакциясендә)

Форма

## ХЕЗМӘТКӘРЛӘР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ

______________________________________________________________,
(министрлык исеме)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) шартлары нигезендә дәүләткә карамаган пенсияне түли башлау кирәк булган затлар::

| Т/с | Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда) | Пенсия нигезе | Түләү ысулы (фонд кассасында кулга алып; почта аша күчереп; банктагы счетка күчереп) |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең пенсия нигезләре барлыкны раслый торган документлар, шул исәптән түбәндәгеләр теркәлә,:

1. Дәүләткә карамаган пенсия билгеләү турында билгеләнгән формадагы гариза.
2. Таныкланган паспорт күчермәсе.
3. Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә пенсия билгеләнүне раслый торган документның таныкланган күчермәсе.
4. Инвалидлык билгеләү турында белешмә күчермәсе – Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән инвалидлык билгеләү белән бәйле пенсия билгеләнә торган хезмәткәрләр өчен.

Министр _______________ _______________________________________________
(имза) (Ф.Ис.Ат.ис.)

М.У.

_______ елның «____» ________________.

______________________________

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы нигезләмәгә 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 декабрь, 1265 нче карары редакциясендә)

Форма

Чыгу №_____________
______ елның «__» __________

________________________________________
(дәүләткә карамаган вәкаләтле
________________________________________
пенсия фонды исеме)

Җитәкчегә ___________________________
(Ф.И.Ат.ис.)

# ЙӨКЛӘМӘ

## ЮЛ-_______________номерлы уртак пенсия счетыннан дәүләткә карамаган пенсияне түли башларга

________________________________________________________________
(Акча салучы оешма исеме)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 584 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджет өлкәсенең кайбер хезмәткәрләрен дәүләткә карамаган пенсия белән тәэмин итү турындагы Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән түбәндәге хезмәткәрләргә:

| Т/с | Нигезләмәнең 3.2 нче пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда) | Пенсия нигезе | Түләү ысулы (фонд кассасында кулга алып; почта аша күчереп; банктагы счетка күчереп) | Йөкләмәне үтәү турында фонд тамгасы (фонд хезмәткәре тутыра) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |

Түләүләр ай саен нигезләмә шартлары нигезендә билгеләнә торган күләмдә башкарыла.

Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең пенсия нигезләре барлыгын раслый торган түбәндәге документлар беркетелә:

1. Дәүләткә карамаган пенсия билгеләү турында билгеләнгән формадагы гариза.

2. Таныкланган паспорт күчермәсе.

3.Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә пенсия билгеләнүне раслый торган документның таныкланган күчермәсе.

4. Инвалидлык билгеләү турында белешмә күчермәсе – Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән инвалидлык билгеләү белән бәйле пенсия билгеләнә торган хезмәткәрләр өчен.

Министр ______________ ________________________________________________
(имза) (Ф.Ис.Ат.ис.)

М. У.

Дәүләткә карамаган вәкаләтле пенсия фонды тамгасы
Кабул итте__________________ ____________ _______________________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.Ис.Ат.ис.)

Керү № ___________ ______ елның «_____» ____________.

___________________________________